| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2018 Иске Иштирәк № 30

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Иске Иштирәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 31 августындагы 6нчы санлы карар белән расланган нотариаль гамәлләр: васыять яисә ышаныч таныклыгы бирүне камилләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы” 2010 елның 27 июлендәге №210-ФЗ Федераль Законга яраклаштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Иске Иштирәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Иске Иштирәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 31 августындагы 6нчы санлы карар белән расланган нотариаль гамәлләр: васыять яисә ышаныч таныклыгы бирүне камилләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5 нче бүлектә:

5.1 пунктның 3нче подпунктында түбәндәге редакциядә:

«3) Заявительдән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Лениногорск муниципаль районы мунципаль хокукый актлары белән каралмаган документ яисә мәгүлъматны, яисә гамәлләрне кылуны таләп итү;

Түбәндәге эчтәлектәге 5.7.1 пункт белән тулыландырырга:

«5.7.1 Заявитель җавабында әлеге бүлекнең 5.7 частенда күрсәтелгән шикаятьне канәгатьләндерергә дип тапканда, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы” Федераль законның 16нчы мәддәсе 1_1 часте буенча каралган, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында, муниципаль хезмәт күрсәтүче, күпфункцияле үзәк яисә оешма гамәлләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп чыккан уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм заявительгә муниципаль хезмәт алу өчен киләчәктәге эш-гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Школьная, 15нче йорт; Бәкер авылы, Нагорная урамы, 38нче йорт, Ялтау, Мир урамы, 27нче йортта урнашкан мәгълүмати стендларда һәм әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Иске Иштирәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы | Н.Ә. Мәҗитов |